СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.07.2018 г г.Мензелинск № 1

**“Татарстан Республикасы “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”**
**Минзәлә муниципаль район Советы карары проекты турында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 44 нче маддәсе, 2005 елның 21 июлендә кабул ителгән “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында”гы 97 нче санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 7 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы карары проектын расларга (Кушымта 1).
2. “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы карары проекты буенча күмәк тыңлаулар үткәрергә.
3.Билгеләргә:
3.1.Күмәк тыңлауларны үткәрү көнен –07.08.2018.
3.2.Күмәк тыңлаулар үткәрү вакыты – 10.00 сәгатьтә.
3.3.Үткәрү урыны түбәндәге адрес буенча: ТР, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 80.
4.Әлеге карарны рәсми урнаштыру тәртибе муниципаль берәмлек Уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастыру (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек Уставында каралган тәртиптә бастырыла (халыкка җиткерелә).
5. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы аппаратына һәм Башкарма комитетына шушы карар проекты буенча күмәк

тыңлаулар үткәрүне, гражданнарны кабул итү һәм тәкъдимнәрен исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Минзәлә муниципаль районы җирле үзидарәсе органнарына карар проектын тикшерү барышында күмәк тыңлауларда әйтелгән һәм кергән тәкъдимнәрне истә тотып эшләп бетерергә, һәм Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы сессиясе каравына кертергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Минзәлә муниципаль район
Советы рәисе А.Ф.Салахов